**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 31 августындагы 3000 номерлы карары**

**Чираттагы финанс елына һәм план чорына**
**Казан шәһәре бюджеты проектын формалаштыру**
**тәртибен раслау турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 9, 169, 184, 185 статьялары һәм Казан шәһәре Думасының 2009 елның 26 ноябрендәге 7-44 номерлы «Казан шәһәре муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында»гы карарының 1 бүлегендәге 12, 19 пунктлары нигезендә **карар бирәм**:

1. Әлеге карарның кушымтасы нигезендә чираттагы финанс елына һәм план чорына Казан шәһәре бюджеты проектын формалаштыру тәртибен расларга.

2. Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең 2008 елның 20 июнендәге 3079 номерлы «Чираттагы финанс елына һәм план чорына Казан шәһәре бюджеты проектын формалаштыру тәртибе турында»гы карарын гамәлдән чыккан дип танырга.

3. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның 31 августындагы
3000 номерлы карары белән
расланды

**Чираттагы финанс елына һәм план чорына**
**Казан шәһәре бюджеты проектын формалаштыру**
**тәртибе**

1. Әлеге тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә әзерләнде һәм чираттагы финанс елына һәм план чорына Казан шәһәре бюджеты проектын (алга таба – шәһәр бюджеты проекты) формалаштыру процессын билгели.

2. Шәһәр бюджеты проекты Россия Федерациясе Бюджет кодексы буенча һәм, Казан шәһәренең чираттагы финанс елына һәм план чорына социаль-икътисади үсешне фаразлауга нигезләнеп, Казан шәһәренең чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү максатыннан формалаштырыла.

3. Шәһәр бюджеты проектын төзүне, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы һәм Казан шәһәре Башкарма комитетының территориаль һәм тармак (функциональ) органнары белән хезмәттәшлек итеп, Казан шәһәре Башкарма комитетының Финанс идарәсе гамәлгә ашыра.

4. Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының икътисади үсеш комитеты түбәндәгеләрне әзерли һәм агымдагы елның 1 августына кадәр Казан шәһәре Башкарма комитетының Финанс идарәсенә тапшыра:

1) агымдагы финанс елының узган чорында шәһәрнең социаль-икътисади үсешенең беренчел нәтиҗәләрен һәм агымдагы финанс елында шәһәрнең социаль-икътисади үсешенең көтелә торган нәтиҗәләрен;

2) шәһәрне социаль-икътисади үсешен фаразлауны.

5. Казан шәһәре бюджеты керемнәренең төп администраторлары агымдагы елның 15 июленә кадәр Казан шәһәре Башкарма комитетының Финанс идарәсенә Казан шәһәре Башкарма комитетының Финанс идарәсе тарафыннан билгеләнгән формалар буенча түбәндәге мәгълүматларны тапшыралар:

- агымдагы финанс елына расланган күрсәткечләрдән һәм финанслар буенча хисап елына факттагы керемнәрдән тайпылышлар сәбәпләрен нигезләп, идарә ителә торган керемнәр буенча агымдагы финанс елына Казан шәһәре

бюджеты үтәлеше буенча көтелә торган бәяләүне;

- түләүчеләр буенча (агымдагы финанс елының өч ае өчен айларга бүлеп) бер тапкыр башкарыла торган түләүләр буенча мәгълүматны;

- керемнәр керүне фаразлауның расланган методикалары буенча исәпләүләр (аңлатмалар) һәм шул исәптән агымдагы финанс елының, чираттагы финанс елының һәм план чорының фаразланган күрсәткечләре финанслар буенча хисап елының фактта башкарылуыннан тайпылу сәбәпләре күрсәтелгән, шулай ук Казан шәһәре бюджеты керемнәрен фаразлауны формалаштыруга тәэсир итә торган башка белешмәләр булган аңлатма язуын теркәп, чираттагы финанс елына һәм план чорына идарә ителә торган керемнәр керүне фаразлау (бюджет классификациясенең идарә ителә торган кодлары буенча).

6. Казан шәһәре Башкарма комитетының җирле һәм тармак (функциональ) органнары, Казан шәһәре Думасы һәм Казан шәһәре Контроль-хисап палатасы:

1) үзләре җаваплы эшчәнлек өлкәсендә билгеләнгән тәртиптә муниципаль программалар, аларга үзгәрешләр кертү турында хокукый актлар проектларын (кирәк булганда) эшлиләр;

2) үз вәкаләтләре кысаларында тиешле төп бүлүчеләргә беркетелгән чыгым йөкләмәләре составын һәм аларны үтәү өчен кирәк булган ассигнованиеләр күләмен оптимизацияләү буенча тәкъдимнәрне гамәлгә ашыралар (төп бүлүченең гомуми чыгымнар күләме чикләрендә);

3) агымдагы елның 15 июленә кадәр, раслаучы документларны һәм исәпләүләрне теркәп, чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджетны формалаштыруның сценарий һәм сценарийдан тыш шартлары буенча бюджет гаризасын җибәрәләр;

4) агымдагы елның 5 августына кадәр югарырак бюджеттан бюджетара трансфертларны бүлү исәпләүләрендә кабул ителә торган беренчел мәгълүматларны (күрсәткечләрне) тиешле республика башкарма хакимият органнарында килештерү үткәрәләр һәм мәгълүматны Казан шәһәре Башкарма комитетының Финанс идарәсенә тапшыралар;

5) агымдагы елның 1 октябренә кадәр муниципаль программалар паспортларын яки әлеге паспортларга үзгәрешләр кертү проектларын тапшыралар;

6) агымдагы елның 15 октябренә кадәр чираттагы финанс елына керем китерүче эшчәнлектән керемнәрнең һәм чыгымнарның фаразлана торган

күләмнәренең карамактагы муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләр буенча бүленешен формалаштыралар һәм тапшыралар;

7) бюджет проектын төзү һәм карап тикшерү өчен кирәк булган башка документларны һәм материалларны тапшыралар (кирәк булган очракта);

8) агымдагы елның 1 ноябренә кадәр карамактагы муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләр тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләрнең норматив чыгымнарын, шулай ук аларны карап тотуга норматив чыгымнарны раслау турында норматив-хокукый актларны эшлиләр һәм раслыйлар.

7. Казан шәһәре Башкарма комитетының Финанс идарәсе;

1) агымдагы елның 5 июненә кадәр бюджет акчаларын төп бүлүчеләргә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджетны формалаштыруның төп ысулларын (агымдагы бюджетның план күрсәткечләре – хезмәт өчен түләү, коммуналь хезмәтләр, туклану, медикаментлар, социаль түләүләр буенча индекс-дефляторларны) җиткерә;

2) Казан шәһәре бюджетының агымдагы финанс елында көтелгән үтәлешенә бәя бирүне тормышка ашыра;

3) чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджетны формалаштыруның сценарий һәм сценарийдан тыш шартлары буенча бюджет акчаларын төп бүлүчеләр тарафыннан тапшырылган бюджет гаризаларын җыюны, гомумиләштерүне һәм анализлауны башкара;

4) җыелма бюджет гаризасы фаразын формалаштырганда, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан җиткерелгән индекс-дефляторларны кулланып, агымдагы елның 1 гыйнварына булган җирле үзидарә органнарының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрен тормышка ашыру белән бәйле чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итүгә каралган агымдагы финанс елына Казан шәһәре бюджетының бюджет ассигнованиеләре нигез буларак кабул ителә;

5) Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына түбәндәге документларны тапшыра:

- чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджетны формалаштыруның сценарий һәм сценарийдан тыш шартлары буенча җыелма бюджет гаризасын фаразлауны;

- раслый торган документларны һәм исәпләүләрне;

- чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына бюджетара трансфертларын исәпләү өчен килештерелгән беренчел мәгълүматларны;

6) Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән Казан шәһәре бюджетының чираттагы финанс елына фаразлау күрсәткечләрен килештерә.

Җыелма бюджет гаризасын фаразлау түбәндәге нигезләр буенча төгәлләштерелергә мөмкин:

- гамәлдә булу вакыты агымдагы финанс елы белән чикләнгән яки чираттагы финанс елында һәм план чорының беренче елында тәмамланачак чыгым йөкләмәләрен гамәлдән чыгару;

- функцияләрне һәм (яки) вәкаләтләрне үзгәртү, җирле үзидарә органнарын, муниципаль учреждениеләрне яңадан оештыру (ликвидацияләү);

- агымдагы финанс елында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан гамәлгә кертелгән объектлар һәм учреждениеләр эшчәнлеген финанс белән тәэмин итү өчен акча бүлү турында карарлар кабул ителгән очракта, муниципаль учреждениеләрне һәм муниципаль милек объектларын файдалануга тапшыру;

- Россия Федерациясе законнарында үзгәрешләр;

- муниципаль белем бирү оешмаларында укучылар һәм тәрбияләнүчеләр контингенты санының үзгәрүе;

- Татарстан Республикасы Рәисе һәм (яки) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан аерым карарлар кабул ителү.

8. Казан шәһәре Башкарма комитетының Финанс идарәсе агымдагы елның 10 ноябренә кадәр Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенә тапшыра:

1) Казан шәһәре Думасының шәһәр бюджеты турындагы карары проектын;

2) чираттагы финанс елына һәм план чорына шәһәрнең бюджет, салым сәясәтенең төп юнәлешләрен;

3) чираттагы финанс елына һәм план чорына төп характеристиклар (керемнәрнең гомуми күләме, чыгымнарның гомуми күләме, шәһәр бюджеты дефициты (профициты)) фаразын;

4) шәһәр бюджеты проектына аңлатма язуын;

5) чираттагы финанс елыннан соң һәм план чорының һәр елыннан соң килә торган елның 1 гыйнварына муниципаль эчке бурычның югары чиген;

6) шәһәр бюджетының агымдагы финанс елында көтелгән үтәлешенә бәя;

7) Казан шәһәренең чыгым йөкләмәләре реестрын;

8) шәһәр бюджеты керемнәре чыганаклары реестрын;

9) Казан шәһәре Думасының шәһәр бюджеты турындагы карары белән муниципаль программалар һәм программалы булмаган эшчәнлек юнәлешләре буенча бюджет ассигнованиеләрен бүлү расланган очракта, муниципаль программалар паспортларын, әлеге паспортларга кертелә торган үзгәрешләр проектларын.

---